| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ГЛАВА<br>НИЖНЕНАРАТБАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТҮБӘН НАРАТБАШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 14 » мая 2021 года № 4

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
Буа шәһәре муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә
«Түбән Наратбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча ачык (гавами) тыңлаулар
уздыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2020 елның 15 маендагы 3-53 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында» карары нигезендә, Түбән Наратбаш авыл җирлегендә яшәүчеләрнең, халык алдында ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән, «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләре турындагы проект буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар уздыруны Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Түбән Наратбаш авыл мәдәният йорты бинасында ТР, Буа районы, Түбән Наратбаш авыл җирлеге, Түбән Наратбаш ав., Совет ур., 2А й. адресы буенча 2021 елның 15 июненә 13:00 сәгатькә билгеләргә.

2. Ачык тыңлауларда тикшерелә торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр Түбән Наратбаш авылы, Совет урамы, 2Б йорт, Түбән Наратбаш авыл җирлеге башкарма комитеты, 3-36-45 телефоны буенча 2021 елның 14 июненә кадәр кабул ителә.

3. Әлеге карарны Түбән Наратбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә :

- ТР, Буа районы, Түбән Наратбаш авылы, Совет урамы, 2А йорт;
- ТР, Буа районы, Бикмураз авылы, Коммуна урамы, 43А йорт;
- ТР, Буа районы, Зур Кырлаңгы авылы, Кооперативная урамы, 8А йорт.

4. Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгының 2020 елның 16 маендагы 2 номерлы «ТР Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча һәм Түбән Наратбаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш
авыл җирлеге башлыгы И.И. Гәлиуллин